ГЛАВА КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Кирова, д.74, с. Катмыш, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

“26 ” октябрь 2020 ел. № 3

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Баскан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Баскан авылы, 1 Май урамы , 70 нче йорт адресы буенча урнашкан Баскан авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 18 нче ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Баскан авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Баскан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Баскан торак пункты Җиңү урамында вак таш түшәп юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Баскан авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Баскан авылы торак пунктында “Әкәч чишмә” сен төзекләндерү (материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);

- Баскан торак пунктында энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, техник хезмәт күрсәтү.

-Баскан авылы елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитетына Баскан авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габидуллин